РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Буа шәһәре

30 апрель 2025 ел № 5-77

ТР Буа муниципаль районы Советының «Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 24 апрелендәге 9-31 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Буа муниципаль районы Советының 2018 елның 24 апрелендәге 9-31номерлы карарына 1 нче кушымта (12.11.2020 ел, № 8-3, 21.10.2022 ел, №4-35, 14.02.2023 ел, №4-40, 28.06.2024 ел, №5-62, 23.01.2025 ел, №6-72 карарлар редакциясендә) «Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен» яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Буа муниципаль районы территориясендәге җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә йөкләргә:

алар чыгарган хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә;

муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләмәгән һәм әлеге органнарны техник тәэмин итү вазыйфаларын башкаручы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү мәсьәләләрен муниципаль район башлыгы белән килештереп, үз хокукый актлары белән бертөрле җайга салырга.

3. Әлеге карар имзаланган вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatrstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов

Буа муниципаль районы Советының
24.04.2018 ел, № 9-31 карарына
1 нче кушымта

(12.11.2020 ел № 8-3,
21.10.2022 ел №4-35,
14.02.2023 ел №4-40,
28.06.2024 №5-62
23.01.2025 ел №6-72 номерлы Буа муниципаль
районы Советы карарлары редакциясендә)

**Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары**

| № т/б | Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Башкарма комитет җитәкчесе | 42 166 |
| 2 | Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 38 319 |
| 3 | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 38 011 |
| 4 | Вәкиллекле орган аппараты җитәкчесе | 38 319 |
| 5 | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 37 857 |
| 6 | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 34 626 |
| 7 | Башкарма комитетның эшләр идарәчесе | 35 549 |
| 8 | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы | 26 623 |
| 9 | Бүлек башлыгы (мөдире) | 28 008 |
| 10 | Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек башлыгы | 28 008 |
| 11 | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы урынбасары | 24 469 |
| 12 | Башкарма комитетның бүлек башлыгы урынбасары, башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 24 469 |
| 13 | Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе, Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе | 24 469 |
| 14 | Баш белгеч | 22 468 |
| 15 | Әйдәп баручы белгеч | 21 083 |
| 16 | 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч | 16 159 |

Буа муниципаль районы Советының
24.04.2018 ел, № 9-31 карарына
5 нче кушымта

(12.11.2020 ел № 8-3,
21.10.2022 ел №4-35,
14.02.2023 ел №4-40,
28.06.2024 №5-62
номерлы Буа муниципаль
районы Советы карарлары редакциясендә)

**Түләүнең күләмнәре һәм тәртибе**
**айлык акчалата бүләкләү**

1. Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш ай саен акчалата бүләкләү дә түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә ай саен акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи окладның 58 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.